КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 июнь г.Казань № 677

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында сыекландырылган табигый газ базарын үстерү» ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 13 май, 317 нче; 2014 ел, 24 сентябрь, 670 нче; 2014 ел, 12 ноябрь, 861 нче; 2015 ел, 26 март, 189 нчы; 2016 ел, 2 декабрь, 889 нчы; 2018 ел, 28 май, 404 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 765 нче; 2019 ел, 22 гыйнвар, 32 нче; 2019 ел, 30 октябрь, 971 нче; 2021 ел, 24 май, 362 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1473 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында сыекландырылган табигый газ базарын үстерү» ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү хакында

2 бүлектә:

2.1 бүлекчәнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Петербург халыкара икътисадый форумы – 2019 кысаларында 2019 елның 7 июнендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте белән «Газпром» гавами акционерлык

җәмгыяте арасында «Татарстан Республикасында табигый газны сыекландыру комплексын төзү» һәм «Татарстан Республикасында автомобильләргә ягулык сала торган криоген станцияләр челтәрен төзү» инвестиция проектларын гамәлгә ашыру буенча килешү имзаланган.»;

2.6 бүлекчәнең 22 нче таблицасыннан соң егерме җиденче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә җир кишәрлекләрен, сатулар үткәрмичә, арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның, масштаблы инвестиция проектының Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен нигезли торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче» сүзләрен «Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 9 июль, 554 нче» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин